СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

11.11.2019 № 36/5
На № __________ от______________

**Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге сатулар үткәрмичә сатыла торган җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибе турында, Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмен билгеләү тәртибе хакында, Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектәге җир кишәрлекләре мәйданы арткан өчен түләү күләмен билгеләү тәртибе турында, Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләренә карата сервитут билгеләү турында килешү буенча түләү күләмен билгеләү тәртибе хакында нигезләмәләрне раслау турында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.4 маддәсе 2 пункты 3 пунктчасы, 39.7 маддәсе 3 пункты 3 пунктчасы, 39.28 маддәсе 5 пункты 3 пунктчасы, 39.25 маддәсе 2 пункты 3 пунктчасы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 44 маддәсе, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Расларга:

1.1. Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге сатулар үткәрмичә сатыла торган җир кишәрлекләренең бәясен билгеләү тәртибе турында нигезләмәне (1 кушымта);

1.2. Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмен билгеләү тәртибе хакында нигезләмәне (2 кушымта);

1.3. Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектәге җир кишәрлекләре мәйданы арткан өчен түләү күләмен билгеләү тәртибе турында нигезләмәне (3 кушымта);

1.4. Тукай муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләренә карата сервитут билгеләү турында килешү буенча түләү күләмен билгеләү тәртибе хакында нигезләмәне (4 кушымта).

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында

(http://tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. Камаев